# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
# **КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме дүртенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы вазыйфасына билгеләп кую турында.
3. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 208-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «2027 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 206-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 205-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү

нормативларын раслау турында» 204-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 186-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 202-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ һәм $19^{5}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 201-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Аерым муниципаль районнарда урнашкан җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән башка категориягә күчерү турында» 198-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 200-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 207-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 22 сентябре
№ 189-VII ДСП